**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «24» апреленнән № 114

## «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында

1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерциясез оешмалар турында» Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы «Мәдәнияттә Россия Федерациясе законнары нигезләре» Россия Федерациясе Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын расларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта)

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәклэштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан эшчәнлектән керем китерүче түләүле хезмәтләр күрсәтү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 августындагы 198 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «24» апреленнән
114 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү прейскуранты

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1 | Дискотека | 30 сум - район мәдәният йорты<br>20 сум - авыл мәдәният йорты, авыл клубы |
| 2 | Бильярд уены (сәгать) | 50 сум - район мәдәният йорты<br>30 сум - авыл мәдәният йорты, авыл клубы |
| 3 | Концертлар, спектакльләр, театральләштерелгән тамашалар, фестивальләр | 100 сум |
| 4 | Социаль - иҗади заказлар буенча түләүле хезмәтләр күрсәтү | 1500 сум |
| 5 | Сәхнә костюмнарын, реквизитларын прокатка алу | Тәүлегенә 500 сум |
| 6 | Озын буйлы курчаклар белән анимация хезмәтләре (1 шт х 1000 сум, 15 минут) | 1000 сум |
| 7 | Озын буйлы курчаклар прокаты | Көненә 500 см |
| 8 | 1 җырга фонограмма яздыру | 700 сум |
| 9 | Музыка уен кораллары прокатка | Сәгатенә 300 сум |
| 10 | Репертуар-методик материаллар сату | 150 сум |
| 11 | Коммерцияле булмаган оешмаларның уртак чараларында өлешләп катнашу | Тулай җыемның 13% ы |
| 12 | Шоу-программа, уен программалары, спорт-сәламәтләндерү хезмәтләре | 50 сум |
| 13 | Күргәзмәләр, һөнәрчелек продукциясе | Сәгатенә 500 сум |
| 14 | Күчермә – күбәйтү үзәге эше | 5 сум,<br>үз кәгазьләре белән бушлай |
| 15 | Кинофильмнар прокаты | 50 сум - олылар билеты<br>30 сум - балалар билеты |

| | | |
|---|---|---|
| | | 20 сум - мәктәпкәчә яшьтәге балалар |
| 16 | Урам экранында реклама урнаштыру | Рәсем рәвешендәге текстлы белдерү (товарлар, хезмәтләр, эш) физик зат өчен тәүлегенә 250 сум,<br>юридик затка - тәүлегенә 500 сум |
| | | Видео – афиша<br>(видео – белдерү)<br>Физик затлар өчен:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 450 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 750 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 1000 сум<br><br>Юридик затлар өчен:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 650 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 950 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 1300 сум |
| | | Бәйрәмнәргә (туган көн, юбилей) видеороликлар<br>Видео:<br>- 30 секундка кадәр – тәүлегенә 1500 сум<br>- 1 минутка кадәр – тәүлегенә 1800 сум<br>- 1,5 минутка кадәр – тәүлегенә 2100 сум |
| | | Фото:<br>- 30 секундка кадәр (10 фотога кадәр) – тәүлегенә 650 сум<br>1 минутка кадәр (20 фото) – тәүлегенә 950 сум<br>1,5 минутка кадәр (25 фото) – тәүлегенә 1300 сум |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «24» апреленнән
114 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмә

Әлеге нигезләмә гамәлдәге законнар, «Мәдәният турында», «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе законнары, РФ Граждан кодексы, РФ Бюджет кодексы, РФ Салым кодексы нигезендә эшләнгән.

Мәдәният өлкәсендә түләүле хезмәтләр «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан гражданнарның рухи ихтыяҗларын һәрьяклап канәгатьләндерү, ял итү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту, матди-техник базаны үстерү һәм мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең матди кызыксынуын арттыру өчен өстәмә финанс чаралары җәлеп итү максатыннан күрсәтелә.

Әлеге нигезләмә түләүле чаралар күрсәтүнең төрләрен, рәвешләрен, тәртибен һәм шартларын (үткәрү урынын, шартнамәчел йөкләмәләрне, касса хезмәтен күрсәтү, ташламалар системасын) билгели һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең тиешле бүлекчәләре һәм хезмәтләре тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

## 1. Түләүле хезмәтләрнең төрләре һәм формалары

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган һәм Яңа Чишмә районы буенча Россия Федераль салым хезмәте инспекциясендә теркәлгән Устав нигезендә гражданнарга күрсәтелә.

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе Устав эшчәнлеге нигезендә түбәндәге түләүле хезмәтләр башкара:

- фестивальләр, смотрлар, конкурслар, күргәзмәләр һәм клуб оешмаларының иҗади эшчәнлеге нәтиҗәләрен күрсәтүнең башка формаларын оештыру һәм үткәрү;
- спектакльләр, концертлар, шоу-программалар, интерактив программалар, башка театр-тамаша һәм күргәзмә чаралары үткәрү;

- төрле йөртүчеләрне кулланып кинофильмнар, мультимедиа программаларын күрсәтү (кинопленка, видеокассеталар, цифрлы тапшырулар);

- лекторийларның, консультацияләрнең, гамәли белем һәм күнекмәләр курсларының эшен оештыру, тематик кичәләр, конференцияләр, презентацияләр, акцияләр, иҗади очрашулар циклы, мастер-класслар, мәгърифәтчелек эшчәнлегенең башка рәвешләре үткәрү;

- массакүләм театральләштерелгән тамашалар, халык күңел ачулары, йөрешләр, гражданлык, гаилә йолалары һәм ритуаллар, бәйрәмнәр (милли, дәүләт, традицион, профессиональ) үткәрү һ. б.;

- мәдәният өлкәсендә төрле халык төркемнәренең ялын оештыру, шул исәптән ял һәм бию кичәләре, дискотекалар, карнаваллар, балалар иртәләре, уен һәм башка мәдәни-күңел ачу программалары;

- профессиональ коллективлар, башкаручылар һәм авторлар катнашында чаралар оештыру;

- клуб уеннары, уен комплекслары, спорт тренажерлары, биллиард, компьютер заллары эшен оештыру;

- төрле мәдәни-ял чараларын әзерләүдә һәм үткәрүдә консультатив, методик һәм оештыру-иҗади ярдәм күрсәтү;

- төрле чыганакларда үз аудио - һәм видеоматериалларын; музыка коралларын; инвентарьларны, реквизитларны, костюмнарны; сәхнә җиһазларын, яктырту һәм тавыш кудыру аппаратураларын, кино-, видео - һәм аудиоаппаратураларны, компьютер техникасын, өстәл уеннарын прокатка бирү;

- репертуар-методик материалларны тормышка ашыру;

- тамаша кую эше буенча хезмәт күрсәтү, биналарны һәм ачык мәйданчыкларны сәнгатьчә бизәү, фонограммаларны язу, сценарийлар, программалар, нигезләмәләр, проектлар язу, реквизит әзерләү буенча хезмәтләр күрсәтү;

- озын буйлы курчаклар белән анимация хезмәтләре күрсәтү;

- озын буйлы курчаклар прокаты;

урам экранында физик затлар һәм юридик затлар өчен рәсемнәр, видео-афиша, видео белдерүләр рәвешендә текстлы белдерүләр формасында реклама урнаштыру;

- урам экранында бәйрәмнәргә (туган көн, юбилей) видеороликлар һәм фотолар урнаштыру ;

- чаралар үткәрү өчен алып баручылар, чараларның музыкаль бизәлеше өчен оркестрлар, ансамбльләр, үзешчән сәнгать коллективлары һәм аерым башкаручылар бирү;

- белешмә, мәгълүмати һәм реклама-маркетинг хезмәтләре күрсәтү; халыкка үз эшчәнлекләре турында җиткерү, шул исәптән Интернет челтәрендәге учреждение сайты аша хәбәр итү;

- фото һәм видеога төшерү хезмәтләре; компьютер хезмәтләре, интернет челтәренә керү мөмкинлеге бирү, ксерокопияләү, сканерлау, документларны төрле чыганакларда тиражлау;

- автоном учреждение профиле буенча сувенир продукция (фотографияләр, открыткалар, каталоглар, видеофильмнар) әзерләү һәм сату;

- түләүле түгәрәкләрдә, студияләрдә, секцияләрдә, шул исәптән мәктәпкәчә яшьтәге балаларда, төрле юнәлешләр буенча курсларда дәресләр оештыру;

- гражданнарга һәм юридик затларга хуҗалык-техник хезмәт күрсәтү белән биналар бирү;

- массакүләм чаралар (юбилей һәм бәйрәм кичәләре, конференцияләр, җыелышлар, семинарлар, профессиональ артистларның концертлары, гаилә бәйрәмнәре, туйлар һ. б.) оештыру һәм үткәрү өчен;

- оешмалар һәм гражданнар гаризалары буенча сценарийлар эшләү, постановкалар ясау, биналарны һәм ачык мәйданчыкларны сәнгатьчә бизәү;

- ваклап сату (ярминкәләр, күргәзмә -сатулар) оештыру өчен.

Әлеге Нигезләмәдә каралган түләүле хезмәтләр төрләре Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана торган түләүле хезмәтләрнең җыелма исемлегенә кертелә. Хезмәт күрсәтүләрнең конкрет исемлеге һәм аларны күрсәтү шартлары «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры тарафыннан билгеләнә һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегендә килештерелә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

## 2. Түләүле хезмәтләргә бәя хасил итү

Түләүле хезмәтләргә бәяләр, чыгымнарның үз-үзен аклау принцибын исәпкә алып, гражданнарның һәр төр хезмәткә ихтыяҗы һәм тәкъдимнәре нигезендә исәпләнә.

Һәр хезмәт төренең үз керем һәм чыгымнар сметасы бар, ул әлеге хезмәт төрен тәэмин итүче белгечләрнең хезмәт хакы, салым түләүләре, коммуналь чыгымнарга, матди-техник базага чыгымнарны, теге яки бу түләүле хезмәт төрен үстерүгә бәйле башка чыгымнарны күздә тота.

Түләүле хезмәтләрнең расланган исемлеге нигезендә һәр төр хезмәтнең үз калькуляциясе бар, ул бер кешегә яки 1 кв.м файдалы мәйданнан чыгып исәпләнә.

Һәр хезмәт төренең калькуляцияләре нигезендә һәм рөхсәт документлары (лицензияләр һәм законда билгеләнгән тәртиптә алынган башка документлар) нигезендә түләүле эшчәнлек өчен бәяләрнең прейскуранты һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең устав эшчәнлеге нигезендә башка төр хезмәтләргә бәяләрнең гомуми прейскуранты төзелә.

Физик һәм юридик затлар өчен чаралар үткәрүгә район Мәдәният йорты көче белән мондый төрдәге хезмәтләр базарында кулай килешү бәясе билгеләнә һәм килешүдә беркетелә.

## 3. Түләүле хезмәтләр тәртибе

Түләүле хезмәтләр физик һәм юридик затларга күрсәтелә. Түләүле хезмәт төренә карап, гражданнар яки юридик затлар һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе арасында килешү төзелә. Килешүдә хезмәт күрсәтү шартлары, якларның бурычлары һәм исәп-хисап тәртибе языла.

Түләүле хезмәт күрсәтү шартнамә шартларына түбәндәгеләр керә:

- гражданнар яки юридик затлар өчен гаилә тантаналары, юбилей даталары, корпоратив кичәләр һәм бәйрәмнәр, туй һәм башка тантаналар уздыру.

Спорт-сәламәтләндерү характерындагы хезмәтләр, дискотекалар, баллар (шул исәптән Яңа ел кичәләре), клуб характерындагы чаралар, Уставларында керү билеты яки «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе боерыгы белән рәсмиләштерелгән абонемент бәяләре буенча түләүле йөрү каралган чаралар.

Һөнәри һәм үзешчән коллективлар концертларына бәяләр «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең прейскуранты тарафыннан билгеләнә.

## 4. Исәпләү тәртибе

Күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләү «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесендә башкарыла.

Корпоратив кичәләргә, юбилейларга, шәхси характердагы гаилә тантаналарына хезмәт күрсәтү өчен түләү, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесендә билгеләнгән тәртиптә расланган катгый хисап документлары булган килешүләрдән файдаланып башкарыла.

Балалар өчен уен программалары, дискотекалар, бию-күңел ачу программалары, киносеанслар, тренажер залына бер тапкыр йөргәндә билгеләнгән тәртиптә расланган керү билетлары кулланыла.

Юридик һәм физик затларга күрсәтелә торган хезмәтләр өчен түләү тәртибе һәм ысуллары килешү шартлары белән билгеләнә.

## 5. Исәп һәм хисап

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе түләүле хезмәтләрнең һәр төре буенча статистик, бухгалтер һәм салым исәбен аерым алып бара.

Бухгалтерия һәм салым исәбе РФ Финанс министрлыгы боерыгы һәм Россия Федерациясе Салым кодексы белән расланган Бюджет исәбе буенча инструкция нигезендә алып барыла.

Исәп-хисапның дөреслеген, смета һәм финанс дисциплинасының үтәлешен контрольдә тоту үзәкләштерелгән бухгалтериягә һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директорына йөкләнә. Күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләме һәм сыйфаты өчен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры тулы җаваплылык тота.

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең һәр филиалы гражданнарга түләүле хезмәт күрсәтүче барлык төрләр буенча да исәп-хисапларны тиешле үрнәктәге билетлар, квитанцияләр нигезендә алып бара.

Филиалда исәпкә алуның дөреслегенә җаваплылыкны филиал директорлары һәм мөдирләре тота һәм контрольлек итә.

## 6. Салым түләү

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә түбәндәге төр салымнар түләү бурычы йөкләнә:

- физик затлар керемена салым (НДФЛ);
- өстәмә кыйммәткә салым (НДС));
- милеккә салым;
- җир салымы;
- транспорт салымы.

РФ НК 2п. 20 пп. 149 статьясы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесен мәдәният өлкәсендә мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түбәндәге хезмәтләргә салым салудан азат итә:

- тавыш техникасы, музыка уен кораллары, сәхнә чаралары, костюмнар, аяк киемен прокатка бирү, ксерокопияләү буенча хезмәт күрсәтү, мәдәни-агарту һәм күңел ачу чараларының тавыш яздыру буенча хезмәт күрсәтү;

-формасы билгеләнгән тәртиптә, катгый хисап бланкы буларак расланган театр-тамаша, мәдәни-агарту һәм тамаша-күңел ачу чараларына керү билетларын һәм абонементларын сату;

- спектакльләргә, концертларга, каталогларга һәм буклетларга программаларны тормышка ашыру.

## 7. Якларның җаваплылыгы

Түләүле хезмәтләрдән файдаланучы кулланучылар билет сатып алырга яки килешүле йөкләмәләр нигезендә тиешле (килешенгән) срокларда күрсәтелгән хезмәт өчен түләргә тиеш.

Кулланучы, килешү шартлары нигезендә, милеккә зыян салса, түли.

Хезмәт алучы үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, ул РФ законнары һәм шартнамә шартлары нигезендә җавап тота.

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан хезмәт күрсәтү һәм аларны үтәү срокларын үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, кулланучы үз теләге белән яңа хезмәт күрсәтү вакытын билгеләргә яки килешүне өзәргә һәм чыгымнарны каплауны таләп итәргә хокуклы.

РФ һәм ТР Законнары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет

мәдәният учреждениесе килешү шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен кулланучы алдында җавап тота. Килешүдә билгеләнгән срокларны бозу «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль закон һәм якларның килешү йөкләмәләрен билгели торган тәртиптә һәм күләмдә неустойка түләү белән бәйле.

Кулланучы белән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе арасында килеп туган дәгъвалар һәм бәхәсләр яклар килешүе буенча яки гамәлдәге законнар нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе йөкләмәләрнең сыйфатсыз яки тулысынча үтәлмәвенә китерүче җиңеп булмаслык хәлләр килеп чыкканда, шулай ук законда каралган башка нигезләр буенча түләүле хезмәтләрне тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

Нигезләмәнең эшләве һәм үзгәрешләр кертү тәртибе

Әлеге Нигезләмәнең гамәлдә булу срогы - 3 ел. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң яңа Нигезләмә кертелә. Законнар яисә учреждение эшчәнлегенең аспектлары үзгәргән очракта, Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә, алар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.